**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Чалпинского сельского поселения**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге**
**Советы**
**БАШЛЫГЫ**

**ул. Центральная, д.39, с. Чалпы, 423324**
**Азнакаевский район**
**Тел. (8-5592) 35-5-46, факс (8-5592) 35-5-46**
**Chal.Azn@tatar.ru**

**Үзәк урам, 39, Азнакай районы**
**Чалпы авылы, 423324**
**Тел. (8-5592) 35-5-46,**
**факс (8-5592) 35-5-46**
**Chal.Azn@tatar.ru**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 30» октябрь 2025 ел №5

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2025 елның 14 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә;

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын уздыру вакыты - 2025 елның 14 ноябрендә 15.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр;

- гражданнар җыенын үткәрү урыны - Чалпы авылы, Үзәк урамы, 24 нче йорт, Чалпы авылы мәдәният йорты залы;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 30 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитетында

гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Чалпы авылы, Үзәк урамы, 24 йорты;

- сайлау хокукына ия булган Чалпы торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

-Чалпы торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2026 елда Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган,

- 1 төркем инвалидларыннан,

- Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан,

- көндезге уку формасында укучы студентлардан,

- махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаилә әгъзаларыннан,

- Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, тоту (Гагарин, Үзәк, Яңа, Бакчалы, Казан, Яшьләр, Ленин урамына вак таш сатып алу, ташу, салу);

- урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алмаштыру, авыл урамнарын яктыртуны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү );

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (үлән чабу хезмәтләре, юлларын һәм территорияләрен кардан чистарту)

« РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы, Үзәк урамы, 39 йорт, Чалпы авылы, Үзәк урамы, 24 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык А.М.Мөхәмәтшин